ISSN 0868-4545



Сәләт күпере

Җәйге әкият – яшел төстә

Борын-борын замандадыр... Кичә дә, бүген дә түгел. Кыскасы, син әле кәбестә барасында чагында Яз, Җәй, Көз һәм Кыш һәммәсе бергә яшәгән ди. Бер өйдә торып, бер гаиләдә гомер кичергәннәр. Җәй мич башында яшәгән, Яз тәрәзә төбендә ди, Көз идәндә, Кыш идән астында ди. Һәм алар бик дус яшәгәннәр. Бер дә талашмаганнар, сатулашмаганнар.

Шуннан соң ни булганмы? Әйе, шуннан соң төрле хәлләр башланган ди. Һәм бу хәлләрнең сәбәпчесе бер җылак кыз белән тыңлаусыз малай булган ди. Җылак кыз тәрәзә янына килсә, үкереп җылый, идәнгә төшсә сөртенеп егыла, мич башына менсә тирләп пешә ди.

Ә тыңлаусыз малай исә мич янына килә дә, Җәйнең яшел юрганыннан тарта, идән асты капкачын ачып, язны шунда таба сөйри ди. Көзгә дә өлеш чыга икән: малай аның сары яфракларын тузгытып йөри ди.

Җылак кызның күз яшьләре исә бар идәнне чылатып бетергән. Көз үзе дә яңгырлы һәм юеш була бит инде ул. Хәтта ул да туйган лычкылдык күз яшьләреннән. «Ыж-жжу-уу!» – дип сызгырган көзнең ачы һәм ачулы җилләре. Ә идән астындагы кышның бу хәлгә җаны өшегән ди. Яз да, ачуы килеп, тәрәзә пәрдәсен тартып куйган. Ә мич башындагы җәйнең чикерткәләре дөнья бетереп сайраган!



© "Салават Күпере", 2002 ел

Тәмам тынычлык югалган бу өйдә. Әлеге җылак кыз белән Тыңлаусыз малай аркасында чып-чын мәһшәр купкан!

Бу хәлгә иң беренче булып Яз гарык булган ди. Ул күп уйлап тормаган, тәрәзәне ачкан да чыгып киткән. Яз артыннан җәй дә мич артыннан сикереп төшеп юк булган. Көз дә идән ярыгына кереп сеңгән. Кыш исә күптән чыгып качкан булган икән инде.

Малай белән кыз бу хәлгә бик аптырап калганнар, хәтта шаккатканнар да әле! Шуннан бирле кыз җылавыннан туктаган, малай һәр әйткән сүзне карусыз тыңлый башлаган. Һәм шул заманнан бирле барлык балалар да бик акыллы, бик әдәпле ди! Дөньяда җылак-мылак кызлар бөтенләй калмаган да!..

Шуның белән бу әкият тә тәмам булган.

Шуның артыннан ук Дөньяда яңа әкият башланган. Әлеге әкият төрлечә аталып йөртелә. Мәсәлән, Көзге, Кышкы әкиятләр, Язгы әкият һәм Җәйге әкият.

Бүген без Җәйге әкияттә яшибез. Ул әкият ямь-яшел төстә.

Ә Көзге әкият нинди төстә? Кышкы әкият нинди төстә? Язгысы нинди төстә була? Син шуларны беләсеңме?

Рәссам Светлана Ибрагимова






Хикмәтле арифметика

Илшат ике балык тотканда, Илфатка бирәү генә каба. Чөнки Марат бертуктаусыз сөйләшеп, балыкларны үзе куркыта. Марат күзен йома да, бер салуда үзенә Илшатка караганда биш тапкыр балык эләккән дип хыяллана. Марат хыялында алты тапкыр салуда ничә балык эләгә?



Гөлназ белән Ләйсән җиләк җыялар. Үзе тапкан алты җиләкнең берсен Гөлназ авызына каба. Ә Ләйсән шул чаклы җиләкнең яртысын авызына озатып бара. Бу кызлар ун минутта унике җиләк тапкан очракта, Ләйсәннең кәрҗин төбендә ничә җиләк булыр?





Эссе көнне дуңгыз бер сәгатькә 6 мәртәбә пычракта аунап чыга. Ә ат бу вакыт эчендә басудан кырык капчык бәрәңге алып кайта. Бер алып кайтуда аның арбасына егерме капчык бәрәңге сыя. Ат сиксән капчык бәрәңге ташыганда, дуңгыз ничә мәртәбә пычракта аунарга өлгерә?

Ләйсән татар кызы. Ләкин ул әтисе белән сөйләшкәндә бер минутка кырык сүз әйтсә, шуның яртысы урыс сүзе була. Аның бер урыс сүзенә каршы әтисе бер мәртәбә: «Син марҗа кызы түгел бит!» – ди. Әти кеше ике сәгать эчендә ничә мәртәбә шулай дип әйтә?



Наил әтисе белән көне буе болында печән чапты. Шул вакыт эчендә аны ун кигәвен тешләде, маңгаена егерме черки кунды. Ә тагын биш кигәвен тешләмәкче булды, тагын ун черки борын очына кунарга теләде.

Болында ул көнне барлыгы ничә кигәвен һәм ничә черки очып йөргән?

Рәссам Илдар НӘФИЕВ



Безнең туган якларда җәй көннәрендә генә эссе була. Бигрәк тә эссе көннәр июль аена туры килә. Ә менә кайбер җирләрдә ел буенча эссе. Мәсәлән, чүлләрдә, сахраларда. Анда нинди хайваннар, гомумән, нинди җан ияләре яши һәм гомер итә икән соң?

Сахраларда, чүлләрдә

Һәр материкта да чүлләр бар: Евразиядә – Гоби һәм Караком сахралары, Америкада – Атакама һәм Моховье чүлләре, Африкада – Сахари, Калахари һәм Намиб, Австралиядә – Виктория.

Әлеге чүлләрдә комнар һәм ташлар кояш астында шулчаклы кыза ки, әгәр алар өстенә йомырка куйсаң, ул тиз арада пешеп чыгачак. Менә шундый эсселектә дә җан ияләре яши бит. Ниләр генә юк анда: бөҗәкләр, үрмәкүчләр, вак ерткыч хайваннар, кошлар, елан һәм кәлтәләр. Гадәттә, алар төнлә генә ауга чыга. Көндезләрен күләгәдә качып яталар. Анда хәтта үзенчәлекле «урманнар» да үсә. Куакларның һәм агачларның тамырлары бик тирәнгә киткән.

Радиатор-колак

Чүлдә яшәү өчен иң җайлашкан хайван фенек дип аталган төлке. Гәүдә озынлыгы 40см гына, ә колаклары – 15 см. Шулар ярдәмендә ул бик шәп ишетә һәм колаклары аша тәндәге эсселек тә чыгып тора. Куркыныч килгәндә фенек тиз арада комга күмелеп ята. Ул сусыз бик озак тора ала.



Кәлтә елан



Агулы тешләр бары тик ике генә төрле кәлтә еланда була. Алар Төньяк Америка чүлләрендә яши һәм исемнәре дә Агулытеш.



«Тере» шар

Бу үсемлек гади розаларга бөтенләй охшамаган. Ул чүлләрдә үсә һәм бары бер генә ел яши. Чәчәк атканнан соң аның ботаклары шар хасил итеп үзәккә бөгелә, ул розага охшап кала. Чүлнең кайнар, коры җилләре аны тамырыннан өзеп ала да, чүл буенча куып йөртә. Әлеге шар-чәчәк үз юлында берәр дымлы җиргә юлыга икән, шулчак могҗиза була: чәчәк егылып китә һәм уңдырышлы җиргә аның орлыклары сибелә.



Кактуслар

Уңдырышсыз җирле чүлләрдә әнә шундый кактуслар үсә ала. Аларның юанлыгы ярты метр, озынлыклары өч катлы йорт биеклегенә җитә. Алар бик акрын, бер елга 3-4 см гына үсә.

Ачы карбыз

Карбызның баллы һәм тәмле икәнен барыбыз да беләбез инде. Әмма карбызның туган ягында – Көньяк Африкада ачы карбыз үскәнен күпләр белми торгандыр әле. Шунысы кызыклы: янәшә үскән ике карбызның берсе ачы, ә икенчесе баллы да булырга мөмкин. Алар бер-берсенә бик охшаган, кабып карамыйча аерып та булмый.



Чүлдә агач үсәме?




Күпләр чүлдә агач үсми дип уйлый торгандыр. Ләкин алар ялгыша. Чүлдә дә агач үсә. Мәсәлән, вельвиния дип аталган агач. Кәүсәсенең озынлыгы бары тик ярты метр, ә юанлыгы ике мәртәбә артыграк. Аның ике генә яфрагы була. Ләкин алар гаҗәп зур – яфракның озынлыгы 6 метр, киңлеге бер метр. Әлеге агач 2 мең яшькә кадәр үсә.

Чүл корабы

Дөя ике төрле була: бер өркәчле һәм ике өркәчле.

Дөя 10тәүлек буена сусыз тора ала. Ә суны берьюлы 130-135 литр эчә ала. Комда батмас өчен дөянең аяклары киң, зур. Аркасындагы өркәче исә аңа азык булып хезмәт итә, сусыз һәм ризыксыз чакта организм өркәчтәге майны үзләштерә.






Рәссам **Диләрә НӘҮРҮЗОВА**

Кадерле дуслар!

Журналның урта битен ипләп кенә алып, кара сызыклар буенча кисегез, сары сызыклар буенча бөкләгез дә килеп чыккан кисәкләрне, бит саннарына карап, китап итеп җыегыз. Булгач-булгач, чын китап булсын — уртасын ике урыннан төпләп куегыз.

©«Салават күпере» китапханәсе.





Бу бакчада ни үсәме?
Гөлләр, чәчәкләр үсә.
Әниләргә биреләсе
Күпме бүләкләр үсә.

Ә бусында ни үсәме?
Бу – яшелчә бакчасы.
Бар табынга куеласы
Яшелчәнең барчасы.

Ә бакчаның монысында
Карлыган, куралар күп.
Алмалары ерактан ук
Чакырып торалар күк.

Нинди бакча, дип тормагыз,
Бу бакчаны күрсәгез.
Бу бакчада ни үсәме?
Бусында – без үсәбез.



„Салават күпере"н укучы нәни дусларыма бәхет телим.

Рафис Корбан.

Әрәмәдә сузып-сузып,
Өзеп-өзеп сайрады.
Ахры, шушы таллыкны ул
Мәңгелеккә сайлады.

Аның шулай моңлануын
Тыңладым мин. Түзмәдем,
Кай ботакка кунып сайрый
Икән соң дип эзләдем.

Эзләдем, тик табалмадым.
Күренмәде анда ул.
Яфрак булып шыткан гүя
Үзе шушы талда ул.

Хәтеремнән чыкмый һич тә
Сандугач сайраулары.
Сандугачлар булып сайрый
Туган якның таллары.



Туп


Туп типкәнне ярата.
Ә типмәсәң, тик ята.
Беләсездер инде сез –
Тик яту бик күңелсез.

Әнием өйдә юкта,
Бүген мин типтем тупка.
Типтем шундый шәп итеп,
Барып тиде шап итеп.

Җиләклектә
Җиләк күп.
Җиләклектә
Чиләк күп.

Һәр малайда
Бер чиләк.
Каян җыярга
Кирәк
Моның кадәрле
Җиләк?


Барыбер булмас
Тутырып,
Ашыйм гына
Утырып.



Безнең өйдә гөлләр күп.
Безнең өй дә гөлләр күк,
Әй күңелле, әй ямьле!
Өйдәге бу гөлләрне
Әби белән бергә без
Су сибеп үстерәбез.

Әби әйтә: «Гөлләр, – ди, –
Тыңлаусыз түгелләр, – ди, –
Көн дә су эчәләр, – ди, –
Шуңа зур үсәләр», – ди.

Безнең өйдә гөлләр күп.
Минем дә шул гөлләр күк
Тизрәк үсәсем килә!
– Әби, эчәсем килә!



Нәрсәгәме? Түшәмгә!
Өлгермәде төшәргә,
Тагын типтем нык кына.
Туп тибү кызык кына!

Ләкин озак тибәргә
Туры килмәде бүген.
Әле тагын бераз мин
Тибә идем тибүен...

Уйлыйсыздыр инде сез
Берәр нәрсә ваткан дип.
Башка да китермисездер
Тубы моннан качкан дип.

Тәрәзәләр, көзгеләр
Исән калды барсы да.
Туп кына, өйдә типмә, дип,
Качты диван астына.




Сөт кибетен караулыйбыз
Абый белән чиратлап.
Ярты көнне үткәрәбез
Кибет ишеген саклап.

«Сөт» дип язган машиналар
Узып йөри тыз да быз.
Ә без, кайчан сөт килер, дип,
Һаман чират торабыз.

Ул авылда рәхәт инде,
Сөт, дип юк баш ватасы.
Бары бер эш – көтү кайткач,
Сыер гына савасы.

Бездә сөтне кибетләргә
Алып килә машина.
Ә авылда өйгә хәтле
Сыер белән ташыйлар.



Ташбаканы кызганам мин.
Ярдәм итәр идем дә...
Үз өен һаман күтәреп
Йөртә, мескен, иңендә.

Бер явызы алып китә
Күрмәсен тагын, диеп,
Шулай күтәреп йөртәдер
Инде, мөгаен, өен.

Соң, ул ташны кемгә кирәк
Диеп беләдер инде?
Һәркемгә өй кадерле шул,
Шуңа күрәдер инде.

Ташбаканың хәлен белдем,
Башкалар да аңлыйдыр.
Өен күтәреп йөргәнгә,
Кызу йөри алмыйдыр.



Гөлгенә Гайсина, 8 яшь.
Азнакай, Чубар Абдул.





Инсаф Исмәгыйлев, 7 яшь.
Чистай, Нарат—Елга.



Раилә Зиннурова, 6 яшь.
Актүбә.



Фәйрүз Хисамиев, 7 яшь.
Ютазы, Каразирек.



Чулпан Исмәгыйлева, 8 яшь.
Чистай, Нарат—Елга.

Балыклар нигә суда яши?

Әүвәл заманда балыклар коры җирдә яшәгән ди. Әллә кайчан инде, әле син өстәл астында бармак суырып утырган чагында ук. Балыклар чирәм чемченгәннәр, агач башларына менеп алма, җимеш ашаганнар. Урманга җиләккә, гөмбәгә йөргәннәр.

Бу балыкларның бер гадәтләре булган: алар көн дә бәйрәм итәргә яраткан. Өстәвенә бик күп сөйләшәләр ди һәм бер-берсен Дәү балыкка гел әләкләп тә торалар икән. Алар бер-берсен чагудан, әләкләүдән үзләре дә туеп беткәннәр. Тик ничек кенә тырышсалар да, начар гадәтләрен ташлый алмыйлар, ди.

Балыкларның тагын бер начар гадәтләре булган: алар иртән битләрен юарга иренгәннәр. Ә суда коенуга килсәк, яр буена аяк та басмаганнар. Чөнки коенырга уйласаң, өс-башны салырга туры киләчәк бит. Ә алар моңа иренгәннәр.

Бер дә бер көнне Дәү балык Алла бабай янына киңәшкә киткән. Хәлне аңлатып җентекләп сөйләп биргән. Алла бабай боларның барысын да үзе күреп, белеп тора икән.

Ул башкаларны җыеп кисәтү ясаган, ачуланган. Ул ачуланганда бик каты күк күкрәгән, яшен яшнәгән. Балыклар аңа: «Төзәлербез, хаталар башка кабатланмас», дип вәгъдәләр биргәннәр. Әмма бераз вакыт узуга вәгъдәләрен тагын онытканнар.

Алла бабай балыкларга икенче мәртәбә кисәтү ясаган, тегеләре тагын гафу сораганнар. Берара вакыт узгач, биргән сүзләрен янә онытканнар. Өченче тапкырында бабай тагын да ачуланган. Бик каты яңгыр коя башлаган, күк күкрәгән, балыклар су астында калганнар. «Суда гына яшәгез алайса, – дигән Алла бабай аларга һәм, – сөйләшмәгез дә!» – дип өстәгән.

Менә шуннан бирле, балык халкы телсез килеш суда гына гомер кичерә ди. Көн-төн суда булгач, иртән бит юасылары да юк, суда чыланмасын дип өс-башларын да салып торасы юк ди.

Әгәр дә мәгәр тәртип бозсалар, Алла бабай судагы балыкларны әле дә булса ачулана ди. Күк күкрәү, яшен яшнәү аның ачуы инде, имеш. Шуңа күрә яшен яшнәгәндә су буена барырга ярамый дип юкка гына әйтмиләрдер. Алайса үзең дә балыкка әйләнеп куюың бар.



Рәссам Фәрит Муллахмәт.





Ләбиб Лерон


Гөлнәзирә – матур кыз

Рәссам Фәрит Муллахмәт

Шалтмылтфильм

Күршебездә бер кыз яши –
Бик матур кызый инде.
Кистергәнгә кадәр чәче
Бигрәкләр озын иде.


Хәер, аңа кыска чәч тә
Килешеп тора үзе.
Гөлнәзирә гүзәлкәйнең
Гел балкып тора йөзе.




Гөлнәзирә телевизор
Карарга бик ярата.
Аның күк кино караучы
Юк безнең Бикнаратта.




Гөлнәзирә китаплар да
Укый – вакыт булганда.
Тәкыяләр үреп кия,
Барса әгәр урманга.




– Үскәч артист буламын! – ди,
Көзгегә баккан саен.
Татлы хыялга бирелә
Йокларга яткан саен.




Өйдә аны һәммәсе дә
Иркәли, назлап сөя:
– Безнең бердәнбер кызыбыз
Бигрәкләр чибәр! – дия...



Аяклары туңмасын, — дип,
Оек бәйли әбисе.
Кайнар ризык ашасын, — дип
Аш пешерә әнисе.



Әтисе дә кибеттән гел
Аңа тәм-томнар ташый...
Тәм-томны бик ярата ул –
Һәммәсен үзе ашый.




Үзе ашый, үзе җырлый,
Күз төшерә көзгегә:
Сокланыплар карап тора
Көзгедәге йөзенә.



Тузан сөртә, идән юа,
Камыр куя әнисе.
Әтисе бәрәңге әрчи,
Суган турый әбисе.



Өйдә беркем эшсез тормый –
Бигрәк эшчән кешеләр.
Гөлнәзирә күлмәк сайлый –
Аның да үз эше бар.



Анда – күлмәк, монда – күлмәк:
Шыплап тулган бүлмәсе.
Бигрәкләр дә матур кыз шул...
Их, ялкау да булмаса...



Конкурс! Мин бит бу?!





Илсөяр, 6 яшь;
Альбина, 4 яшь.

– Без җырлыйбыз, җырлыйбыз ла,
Без биибез, биибез...
Без җырлап-биеп үскәнгә
Матур безнең өебез!
(Мөслим, Урәзмәт)





Раил, 1 яшь 2 ай.

– «Кәнфит бирәм», – дигән булып,
Ник мине хәйләлисез.
«Аягым авырта!» – дим ич,
Ник бер дә жәлләмисез?
(Кукмара, Вахит)





Илшат, 8 яшь;
Инзил, 3 яшь.



– «КамАЗ»ыма утырдым да
Кочакладым абыйны...
Сурәт әйбәт чыгар микән?
Шулай төшсәк ярыймы?!
(Азнакай, Тымытык)



Миләүшә, 8 яшь;
Камилә, 8 яшь;
Айсылу, 7 яшь.

– Каретага өчебез дә
Бергә сыйдык – күрегез...
Әле тагын урын калды,
Йә, берегез керегез!
(Башкортостан, Туймазы, Төмәнәк)





Илшат, Рәзинә, Лилия.


– Алар... алар парлаштылар,
Бәхетлеләр шуңа да.
Ә мин... ә мин җылыйм менә...
Яр табыгыз миңа да!
(Апас, Борнаш)

Башваткычлар



Кәли, Вәли һәм Сәлим
Утыра кармак салып...
Йә, кем кайсы балыкны
Тизрәк тартып алыр?

Ребус



Рәссам Фәрит Муллахмәт

Әлеге балык-рәсемдәге буш шакмакларга түбәндәге балык исемнәрен дөреслэп яз:

...лабуга, ...ыртлак..., ...уда..., ...ызылкана..., ...әртә..., ...ашба... .

Салават күпере

7(148) — 2002

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭЛЕМТӘ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле чыга.

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства связи РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке. Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде.

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Фидель ХӘСӘНОВ

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
.Алла АЙСИНА рәсемнәре,

Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм тесләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Производствога бирелде 10.7.2002 ел.
Басарга кул куелды 10.7.2002 ел.
Кәгазь форматы 60х100 1/16.
Гарнитура – Прагматика.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 14948 данә. Заказ Б-349.
Бәясе килешү буенча.

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

Ләбиб Лерон

Җәйге бәхәс

Җәйнең ямьле бер көнендә,
Яр буенда – чирәмдә
Өч малай бәхәс куерта
Керми генә тирәнгә...

– Бәхәсләшеп торасы юк,
Җәй – минем җәй! – ди Һашим. –
Җәй көнендә бертуктаусыз
Иң күп җиләк мин ашыйм!

– Булышам әти-әнигә
Печән әзерләшергә...
Шуңа бу җәй – минем җәй! – дип
Сүзен бирми Бәшир дә.

– Җәй көнендә мин туганмын –
Минем җәй! – ди Фасил да...
...Җәй ул барчабызныкы да,
Уйлап баксаң, асылда.